КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 ноябрь г.Казань № 1040

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 941 нче карары белән расланган Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 941 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1349 нчы, 2022 ел, 29 апрель, 402 нче, 2023 ел, 22 март, 318 нче, 2023 ел, 31 май, 664 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.13. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторы түбәндәгеләр:

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендә яисә төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территориясенең саклау зонасы чикләрендә урнашкан җир (урман) участокларында сирәк очрый торган һәм

юкка чыгу куркынычы яный торган үсемлекләр төрләренең алдагы өч ел дәвамында 20 проценттан күбрәккә кыскаруы;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигый территорияне яисә төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигый территорияне саклау зонасын пычрату турында мәгълүмат керү;

гражданнар, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын алу, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контрольдә торучы затлар тарафыннан Дәүләт комитетына хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында дөрес булмаган мәгълүмат бирү турында мәгълүмат алу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин